ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел. (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamamadysh. ikrayona@tatar. ru, www. mamadysh.tatarstan. ru

**Карар** Карар

№ 572 "23" 05 2017 ел

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
башкарма комитетының
14.03.2017ел, № 284 карарына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2017 елның 24 апрелендәге 28-0-21/17 хокукый экспертиза бәяләмәсен карап, 2007елның 13 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 14 мартындагы «2017 елның 1 кварталына салым салынырга тиешле гражданнарның кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында» 284 номерлы карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2017 елга салым салынырга тиешле гражданнарның кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында».

1.2. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын 2017 елга муниципаль торак фондында гражданнарның аз керемле булуын тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында әлеге карарга 1 нче кушымтада билгеләнгән исәп-хисап нигезендә 2017 елга бирергә».

1.3. Карарга 1 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2017 елга муниципаль торак фондында социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында.Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын билгеләү, гражданнарны аз керемле дип тану турында»

1.4. Карарга 1 нче кушымтаның 1 пунктында РЦ исәпләү күрсәткечен түбәндәге редакциядә санарга: «РЦ - Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. уртача базар бәясе».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Э. Фәттахов